**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ЛЬЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛЬЯШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422375 с. Льяшево, ул. Пролетарская, 22А

422375 Льяш авылы, Пролетар урамы, 22А

тел., факс (84373) 55-8-26, e-mail: Lsv.tet@tatar.ru
ОГРН 1021606556971, ИНН/КПП 1638001624/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .11. 2023** **№ 30-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль Законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проектын (алга таба – Устав проекты) беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Устав проекты буенча комиссия составын кушымтага ярашлы расларга
№ 2.
3. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Льяш авылы, Совет урамы, 21а; Олы Бисәр авылы, Заовражная урамы, 33 йорт; Ямбакты авылы, Октябрьнең 60 еллыгы урамы, 24а йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru.
7. Устав проекты буенча 2023 елның 22 декабренә 14:00 сәгатьтә Льяш авыл мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар билгеләргә.
8. Устав проекты буенча Комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Устав проектын тикшерү һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.
9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге башлыгы И.А. Тихоновага йөкләргә.

**Җитәкче** **И.А. Тихонова**